**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.12.2015 № 917

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 12 гыйнварында теркәлде, № 3162

Балигъ булмаган һәм эшсез гражданнарга
алар вакытлыча эшкә урнашкан чорга
2016 елда матди ярдәм күләмнәре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының мәшгульлегенә булышлык итү" дәүләт программасын раслау турында" 09.08.2013 № 553 карарына туры китереп **боерык бирәм:**

2016 елда матди ярдәм күләмнәрен түбәндәгечә билгеләргә:

14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарга – алар вакытлыча эшкә урнашкан чорга эшсезлек буенча бер кешегә бер айга бирелә торган пособиенең 1,5 кә кабатлы минималь зурлыгына тигез итеп;

түләнелүче җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга – эшсезлек буенча бер кешегә бер айга бирелә торган пособиенең 2,5 кә кабатлы минималь зурлыгына тигез итеп;

эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарга – алар вакытлыча эшкә урнашкан чорга эшсезлек буенча бер кешегә бер айга бирелә торган пособиенең 2,5 кә кабатлы минималь зурлыгына тигез итеп;

урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарга – эшсезлек буенча бер кешегә бер айга бирелә торган пособиенең 2,5 кә кабатлы минималь зурлыгына тигез итеп;

гомуми белем бирү мәгариф оешмаларын һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлаганнар исәбендә булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарга – эшсезлек буенча бер кешегә бер айга бирелә торган пособиенең 2,5 кә кабатлы минималь зурлыгына тигез итеп.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**